ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«__7__»__декабрь__ 2018 ел** **№ 1218**

**2019 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендщ Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне 2019 елга расларга:

Арча муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне матди карап тотуга норматив чыгымнар;

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә түбәндәгеләр раслаган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

"2019 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында Һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында" 2018 елның 24 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

Әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары З.З.Шәрәфетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин

Расланды
Арча муниципаль районы башкарма комитетының «__» ___________ 20__ № ____карары белән

**Арча муниципаль районы**
**гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга**
**НОРМАТИВ чыгымнар**

| гомуми белем бирү оешмасы тибы һәм төре | Территориаль урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә елына норматив чыгымнар |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 89268 |
| | авыл җирлеге | 90630 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 135418 |
| | авыл җирлеге | 139893 |